РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» июль 2022 ел Олы Кайбыч ав. № 127

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы Рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү турында» 2020 елның 15 нче июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы Рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү турында» 2020 елның 15 нче июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) класс чины өчен айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә:

| Клас чины | Класс чины өчен өстәмә түләү күләме, вазыйфаи окладка карата процент |
|---|---|
| I классны хакыйкый муниципаль киңәшче<br>I классны муниципаль киңәшче<br>I классны муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>I классны муниципаль хезмәт референты | 7 |

| | |
|---|---|
| I классłы муниципаль хезмәт секретаре | |
| II классłы хакыйкый муниципаль киңәшче<br>II классłы муниципаль киңәшче<br>II классłы муниципаль хезмәт Киңәшчесе<br>II классłы муниципаль хезмәт референты<br>II классłы муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| III классłы хакыйкый муниципаль киңәшче<br>III классłы муниципаль киңәшче<br>III классłы муниципаль хезмәт Киңәшчесе<br>III классłы муниципаль хезмәт референты<br>III классłы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

Муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына караганда муниципаль хезмәт вазыйфаларының югарырак вазыйфасына билгеләгән очракта, аның класс чины өчен оклад күләмен аның биләгән вазыйфасы кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин биргәнчегә кадәр исәпләп чыгару вазыйфаи окладның процент ставкасыннан 3 процентына тигез була.

Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәткәр элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбәнрәк төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгән очракта һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класслы чин бирелгән булса, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладның 7 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Р. Г. Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин